ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында
закон проекты эшенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларга 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә закон проектларын үз вакытында әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле комитетлары эшчәнлеген җайга салучы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарларына 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планына кертелгән закон проектларын әзерләү срокларын үтәүне контрольдә тотарга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 163-VII ДС

2024 елның 23 декабрендәге
163-VII ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
кушымта

**2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы**

| № т/б | Проектның исеме | Закон чыгару инициативасы хокукы субъекты | Проектны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итү срогы |
|---|---|---|---|
| **1. Дәүләт корылышы** | | | |
| 1. | «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бота урман хуҗалыгы авылын, Хазовка поселогын бетерү һәм «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы советы | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә законнарны камилләштерү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын бозган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | I квартал |
| 3. | «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Норма, Сасна авыл җирлекләре һәм «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территорияләре чикләрен үзгәртү өлешендә) | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы советы | II квартал |
| 4. | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» һәм «Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы советы | II квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Республикасы законы проекты | | |
| 5. | «Татарстан Республикасы Арча районы Курса тимер юл разъезды поселогын бетерү һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы советы | II квартал |
| 6. | «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты (Татарстан Республикасы законнарына туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты | II квартал |
| 7. | «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты | III квартал |
| 8. | «Татарстан Республикасы Кукмара районының Саз-Тамак тимер юл разъезды поселогын бетерү һәм «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы советы | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (күрсәтелгән закон актларының аерым нормаларын «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закондагы үзгәрешләргә туры китерү максатыннан) | Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе | IV квартал |
| **2. Икътисадый сәясәт** | | | |
| 10. | «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү мәсьәләсен хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә федераль законнарга туры китерү максатыннан) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | I квартал |
| 11. | «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (аеруча куркыныч хайван авырулары чыганакларын юкка чыгарганда хайваннарны һәм (яисә) терлекчелек продукциясен алып китү мәсьәләләрен җайга сала торган нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә федераль законнарга туры китерү максатыннан) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. | «Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | I квартал |
| 13. | «2024 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Рәисе | II квартал |
| 14. | «2024 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Рәисе | II квартал |
| 15. | «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | II квартал |
| 16. | «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (капиталь ремонт ясауны оештыру өлкәсендә башкарма хакимият органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | III квартал |
| 17. | «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | финанс комитеты | |
| 18. | «2026 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 19. | «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүләр кысаларында башкарыла торган инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу өлешендә федераль законнарга туры китерү максатыннан) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты | IV квартал |
| 20. | «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Рәисе | IV квартал |
| 21. | «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Рәисе | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **3. Социаль сәясәт** | | | |
| 22. | «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты («Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуны тыю турында һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәреш кертү хакында» Федераль закон белән балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләр сатуны тыюны билгеләүгә бәйле рәвештә мондый тыю турындагы нигезләмәне төшереп калдыру максатыннан) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | I квартал |
| 23. | «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | II квартал |
| 24 | «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты | | |
| 25. | «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 26. | «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты | IV квартал |
| 27. | «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (хезмәт ветераннарының социаль ярдәмгә мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү өчен хезмәт | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Е.И. Кузьмичева | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ветераннарының уртача айлык кеременең чик күләмен арттыру максатыннан) | | |
| **4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативалары** | | | |
| 28. | «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты (проект документациясен әзерләү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Р. Усманов | I квартал |
| 29. | «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (күпфатирлы йортларда, күпфатирлы йортларга кушып төзелгән һәм кушып-өстәп төзелгән биналарда урнашкан сәүдә һәм җәмәгать туклануы оешмаларында сатучының (башкаручының) эш режимын җирле үзидарә органнары карары буенча билгеләү өлешендә) | Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы | III квартал |
| 30. | «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты (сыра һәм сыра эчемлекләре, сидр, пуаре, әче бал җитештерүне лицензия алына торган эшчәнлек төрләренә кертү өлешендә) | Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы | III квартал |